

Регина Солдаткина Н.П.Огарев исе-мендәге МГУнын юридик факультеты гражданлык-хокукый профиль буенча белгечлек әзерләv бvлегендә 4 курста укый. Сойкемле, максатчан кыз белем дә ала, эшли дә.
– Киләчәк профессиямне озын-озак сайладым, анын турында кvп уйлар уйладым, – ди студентка. – Башта ведомственный вузга укырга керергә, зур шәһәрдә яшәргә хыялланган идем. Ә соныннан Мордовиядә яшәргә һәм эшләргә тиешлегемне анладым. Туган ягынны, республиканны матурлатырга кирәклегенә тошендем. Мәктәпне тәмамлагач, документларымны МГУ-нын юридик факультетына тапшырдым. Бирегә укырга керvемне дорес юлдан киттем дип саныйм.  Университетыбызда укырга кызыклы, тик ялкауланма гына!
Максатына тугъры ул. Регина югарыда билгеләгән тормыш кагыйдәләренә кон саен ашкына һәм нәтижәләре дә озак коттереп тормый: югары белем йортында баштагы оч уку елында тик югары академик стипендия алып укый, ә дvртенче курста - Россия Федерациясе Правительство стипендиаты була! Бар яктан да актив Регина Солдаткина гражданлык, жинаять, хезмәт хокукы буенча вуз, регионара һәм ботенроссия олимпиадалары призеры һәм жинvчесе, студентларнын фән жәмгыятьчелеге әгъзасы; vзенен фәнни язмалары бар.
- Мина, киләчәктә хезмәт юнәлешен сайлау очен, «Юриспруденция»нен зур спектрда булуы – дәvләт хезмәте, шәхси практика, корпоратив сфера һәм хәтта укыта алу момкинчелеге ярдәм итә, – дип уртаклаша Регина. – Бу киләчәк тормышыбызны теләгәнчә, олы ометләр куеп тозергә ярдәм итә. Яулыйсы vрләр кvп әле...
Уку белән параллель рәвештә, Регина Солдаткина юридик фирмада хезмәт итә. Бу ана остәмә тәжрибә тупларга ярдәм итә. Регина вакытын файда белән vткәрергә ярата; яна белем аны кызыксындыра. Ул укыган факультетынын «Комета» педагогик отряды составында Подольск шәһәре янында урнашкан «Мечта» лагеренда вожатый булып та эшли, ә Саранскта футбол чемпионаты vткән вакытта волонтер була – чит ил кунакларын ташырга ярдәм итә. Бер минутын бушка vткәрми!
- Туганнарын дусларын белән аралашырга вакытын каламы, - дип кызыксынам.

- Сез нәрсә, - дип елмая ул, – ял итәргә, яраткан эшем белән шогыльләнергә һәм дусларым, туганнарым белән аралашырга да вакыт табам. Үземнен туган Кочкурово районы Качелай авылымны, андагы туган йортымны бик тә яратам һәм һәр атна әти-әнием янына киләм; дусларымны да алып килгәлим. Мин әни-әтиемне бик тә яратам, аларга чиксез рәхмәтлемен.
Регина Солдаткина алга куйган планнары белән дә уртаклашты: бакалавриатны тәмамлагач, читтән торып магистратурада укырга уйлый. Ә алган белемен тормышка ашыру очен, эшләргә тели. Тагы хыялында икенче югары икътисади (экономическое) белем алу.
Студент еллары – искиткеч матур чак. Кемнәр очендер студент еллары инде артта калып, сагынып сойләр хатирәләре генә кvнел кылларын чиртә. Бvгенге кондә ул исемне горур йортvче студент яшьләребезгә дә ак конләшv белән конләшеп тә, сокланып та карыйбыз. Ә бит студент чакта сайлаган профессия алу белән бергә яна момкинчелекләр, перспективалар ачыла; чын дуслар барлыкка килә. Бу планлаштыру һәм ышанулар вакыты. Һәм аларнын, хаттә ин-ин амбициозларынын, тормышка ашуына ышанасы килә. Яулагыз биек vрләрне...

**Н.Хәлил**